ГЛАВА АБСАЛЯМОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.2,
с.Абсалямово, 423957

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яшьләр урамы, 2 йорт,
Әбсәләм авылы, 423957

Тел.:(85593) 4-26-79, факс:4-26-79, e-mail: Absal..Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№3** **14 ноября 2019 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1. , 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. 2019 елның 23 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Әбсәләм авыл җирлеге Әбсәләм авылы, Советский урамы, 50Г нче йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Әбсәләм авылы гражданнары җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

"Сез 2020 елда Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Әбсәләм авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Әбсәләм авылы Советлар урамы буенча юлны асфальтлауга;

«ӘЙЕ» “ЮК".

3. Әбсәләм авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

4. Әлеге карарны ул кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында  һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы:                    Р.Г. Мөхәммәдвафин